КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 19 май г.Казань № 403

**Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда Казан метрополитены инфраструктурасы объектларының ремонт һәм торгызу эшләрен (метрополитенның 1 нче линиясендәге 1 нче участогында су үтүләрне бетерүне кертеп) үткәрү өлешендә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда Казан метрополитены инфраструктурасы объектларының ремонт һәм торгызу эшләрен (метрополитенның 1 нче линиясендәге 1 нче участогында су үтүләрне бетерүне кертеп) үткәрү өлешендә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 19 май, 403 нче
карары белән расланды

# Халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда Казан метрополитены инфраструктурасы объектларының ремонт һәм торгызу эшләрен (метрополитенның 1 нче линиясендәге 1 нче участогында су үтүләрне бетерүне кертеп) үткәрү өлешендә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу өчен 2020 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Бу Тәртип халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда Казан метрополитены инфраструктурасы объектларының ремонт һәм торгызу эшләрен (метрополитенның 1 нче линиясендәге 1 нче участогында су үтүләрне бетерүне кертеп) үткәрү өлешендә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулы күләмдә финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге (алга таба – муниципаль берәмлек) бюджетына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү механизмын билгели.

2. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган башка бюджетара трансфертлар белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

3. Башка бюджетара трансфертлар муниципаль берәмлек бюджетына 2020 елга Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

4. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына түбәндәге шартларда бирелә:

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чаралар исемлеген раслый торган муниципаль хокукый акт булганда;

муниципаль берәмлек бюджетында (муниципаль берәмлек бюджетының җыелма бюджет исемлегендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган чаралар исемлеген тормышка ашыру буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булганда;

финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча муниципаль берәмлекнең йөкләмәләрен күздә тота торган килешү (алга таба – килешү) төзегәндә һәм әлеге килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылык булганда.

5. Башка бюджетара трансфертларны алу өчен муниципаль берәмлек Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

башка бюджетара трансфертлар бирү турында ирекле рәвештә язылган, кергәннән соң эш көннәрендә исәпләнә торган бер көн эчендә теркәлә торган заявка (алга таба – заявка);

муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карарыннан вәкаләтле зат тарафыннан расланган һәм муниципаль берәмлек бюджетында Татарстан Республикасы бюджетыннан бирергә планлаштырыла торган башка бюджетара трансфертларны үз эченә алган чаралар исемлеген тормышка ашыру буенча муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булуны раслый торган агымдагы финанс елына муниципаль берәмлек бюджеты (җыелма бюджет исемлеге) турында өземтә;

финанс-икътисадый нигезләүне теркәп, Казан метрополитены инфраструктурасы объектларының ремонт һәм торгызу эшләрен (метрополитенның 1 нче линиясендәге 1 нче участогында су үтүләрне бетерүне кертеп) үткәрү буенча эшләр башкаруга чыгымнар сметасын.

6. Башка бюджетара трансфертлар бирү яки аларны бирүдән баш тарту турында карар Министрлык тарафыннан заявка теркәлгән көннән бер эш көне эчендә кабул ителә.

7. Башка бюджетара трансфертларны бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

муниципаль берәмлек тарафыннан бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары үтәлмәү;

бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

бу Тәртипнең 5 нче пунктында каралган документлардагы мәгълүмат дөрес булмау;

тапшырылган документлар, алардагы мәгълүматлар бу Тәртиптә каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәү.

8. Заявканы кабул итмәү сәбәпләре күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны бирүдән баш тарту турындагы хәбәрнамә Министрлык тарафыннан муниципаль берәмлеккә заявка теркәлгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә җибәрелә.

9. Муниципаль берәмлек заявканы кабул итмәү турындагы хәбәрнамәне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә бу Тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән яңадан заявка бирергә хокуклы.

10. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкның башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы карары кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча төзелгән килешү нигезендә бирелә.

11. Килешүдә түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның күләме, аларның максатчан билгеләнеше;

бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткеченең мәгънәләре;

башка бюджетара трансфертларны күчерү тәртибе;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече мәгънәсенә ирешү турында хисаплылык бирү тәртибе һәм формалары;

муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсенең) билгеләнгән күрсәткеченә ирешмәү нәтиҗәләре;

муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләрнең үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

якларның килешү шартларын бозган өчен җаваплылыгы.

12. Муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$P = \sum_{j=1}^{n} N_{(j)},$$

монда:

P – муниципаль берәмлек бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

$N_{(j)}$ – Казан метрополитены инфраструктурасы объектларының ремонт һәм торгызу эшләрен (метрополитенның 1 нче линиясендәге 1 нче участогында су үтүләрне бетерүне кертеп) үткәрүнең эшләр төрләре буенча бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән смета нигезендә билгеләнә торган чыгымнар күләме;

n – Казан метрополитены инфраструктурасы объектларының ремонт һәм торгызу эшләрен (метрополитенның 1 нче линиясендәге 1 нче участогында су үтүләрне бетерүне кертеп) үткәрү буенча эшләр төрләре саны.

13. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге (нәтиҗәсе) күрсәткече (алга таба – нәтиҗәлелек күрсәткече) булып метрополитенның күчмә составы белән пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашырганда транспорт хезмәте күрсәтү ышанычлылыгы тора; ул «метрополитенның күчмә составы белән даими йөртүләр маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты» күрсәткече ярдәмендә бәяләнә, аның мәгънәсе ≥ 0,96 була.

Хисап чоры өчен метрополитенның күчмә составы белән даими йөртүләр маршрутлары расписаниесен үтәү коэффициенты ($К_{расп}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$К_{расп} = \frac{Q_{рейсрасп}}{Q_{рейс}} \geq 0{,}96\,,$$

монда:

$Q_{рейсрасп}$ – хисап чоры өчен метрополитенның күчмә составы белән пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашырганда расписание белән билгеләнгән вакыт эчендә яки хәрәкәт расписаниесеннән рөхсәт ителгән тайпылышлар чикләрендә башкарылган рейслар саны;

$Q_{рейс}$ – хисап чоры өчен метрополитенның күчмә составы белән пассажирлар йөртүләрне гамәлгә ашырганда рейсларның гомуми саны.

Нәтиҗәлелек күрсәткече мәгънәләренә ирешүне бәяләү Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 14 нче пунктында күрсәтелгән һәм муниципаль берәмлек тарафыннан бирелгән хисаплар нигезендә гамәлгә ашырыла.

14. Муниципаль берәмлек башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 гыйнварына кадәр Министрлыкка финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып башка бюджетара трансфертлар торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын гамәлгә ашыру турында һәм нәтиҗәлелек күрсәткеченең ирешелгән мәгънәсе турында килешү белән күздә тотылган тәртип һәм форма нигезендә хисаплар кертә.

15. Татарстан Республикасы бюджетыннан муниципаль берәмлек бюджетына башка бюджетара трансфертлар акчасын күчерү Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә керүләрне исәпкә алу һәм аларны Россия Федерациясенең бюджет системасы бюджетлары арасында бүлү өчен Федераль казначылыкның территориаль органына ачылган счетка Министрлык тарафыннан бу Тәртипнең 10 нчы пунктында күрсәтелгән килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә гамәлгә ашырыла.

16. Муниципаль берәмлек бирелә торган хисап мәгълүматларының дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертларның максатчан файдаланылмавы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

17. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

18. Әгәр дә башка бюджетара трансфертлар бирү елының 31 декабре хәленә карата муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган йөкләмәләр бозылуга юл куелса һәм башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елда килешүдә каралган нәтиҗәлелек күрсәткече мәгънәләренә ирешү турында хисаплылык бирү датасына кадәр вакыт эчендә әлеге бозулар бетерелмәсә, башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме ($V_{кире\ кайтару}$) түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$V_{кире\ кайтару} = (P \times D) \times 0{,}1,$$

монда:

$V_{кире\ кайтару}$ – муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләме;

P – хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләме;

D – башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты.

19. Муниципаль берәмлек бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиешле акча күләмен исәпләп чыгарганда хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләмендә башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше исәпкә алынмый.

20. Башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$D = 1 - \frac{T}{0{,}96},$$

монда:

T – хисап чоры өчен нәтиҗәлелек күрсәткеченең фактта ирешелгән мәгънәсе;

0,96 – нәтиҗәлелек күрсәткеченең план буенча мәгънәсе.

21. Муниципаль берәмлек тарафыннан башка бюджетара трансфертлар максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аларны бирү шартлары бозылган, шул исәптән муниципаль берәмлек тарафыннан акча Татарстан Республикасы бюджетына бу Тәртипнең 18 нче пункты нигезендә кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган бюджетка мәҗбүри түләтү чаралары кулланыла.

22. Башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 гыйнвары хәленә карата акчаның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемenә Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

23. Бу Тәртип нигезендә бирелгән башка бюджетара трансфертлардан максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.